**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 1 июле** **№ 45**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2017 елның 10 декабрендәге 111 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 293-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның тәртибе һәм шартлары турында нигезләмә» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2017 елның 10 декабрендәге 111 номерлы карарының 1 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4.14 пунктта:

беренче абзацта «муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы) » сүзләрен «муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнары (программалары)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлеге пунктта күрсәтелгән муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүматны урнаштыру өчен «Интернет» челтәрендә рәсми сайт булып Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән торглар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен Россия Федерациясенең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты тора (алга таба - «Интернет» челтәрендә рәсми сайт). Әлеге пунктта күрсәтелгән муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турындагы мәгълүмат өстәмә рәвештә «Интернет» челтәрендәге сайтларда урнаштырыла.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы

Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә.Габидуллинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы**
**Кама Тамагы муниципаль район Советы рәисе Н.А.Вазыйхов**